БАЛТАСИНСКИЙ РАЙОННЫЙ
ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БАЛТАЧ РАЙОН
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«__14__» __10___ 2019 г. № _323_

**Татарстан Республикасы Балтач районы башкарма комитетының вазыйфаи затлары тарафыннан гражданнар мөрәҗәгатьләрен карау һәм шәхси кабул итү тәртибен раслау турында**

«Россия Федерациясе гражданнары мөрәҗәгатьләрен карау тәртибе турында» 2006 елның 2 маендагы 59-ФЗ номерлы Федераль законына (алга таба - 2006 елның 2 маендагы 59-ФЗ номерлы Федераль закон), «Татарстан Республикасында гражданнар мөрәҗәгатьләрен карау тәртибе турында» 2003 елның 12 маендагы 16-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына Һәм «Татарстан Республикасында гражданнар мөрәҗәгатьләре турында «2014 елның 24 июлендәге 75-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына нигезләнеп, Татарстан Республикасының Балтач районы башкарма комитеты **карар бирә**:

1. Татарстан Республикасы Балтач районы башкарма комитетының вазыйфаи затлары тарафыннан гражданнар мөрәҗәгатьләрен карау һәм шәхси кабул итү тәртибен расларга.

2. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында» бастырып чыгарырга һәм Балтач муниципаль районының рәсми сайтында (baltasi.tatarstan.ru) урнаштыу юлы белән халыкка игълан итәргә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитетының оештыру-гомуми бүлеге җитәкчесенә йөкләргә.

Җитәкче А.Ф.Хәйретдинов

Татарстан Республикасы
Балтач район башкарма комитетының
2019 елның _14 октәбренең_
_323 нче_номерлы карарына кушымта

## 1. Гомуми нигезләмәләр.

1.1. Татарстан Республикасы Балтач районы башкарма комитетының вазыйфаи затлары тарафыннан гражданнар мөрәҗәгатьләрен карау һәм шәхси кабул итүнең әлеге Тәртибе (алга таба - Тәртип) "Россия Федерациясе гражданнарының мөрәҗәгатьләрен карау тәртибе турында" 2006 елның 2 маендагы 59-ФЗ номерлы Федераль закон (алга таба - 2006 елның 2 маендагы 59-ФЗ номерлы Федераль закон), "Татарстан Республикасында гражданнар мөрәҗәгатьләре турында" 2003 елның 12 маендагы 16-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, "Татарстан Республикасында гражданнарның мөрәҗәгатьләрен карау тәртибе турында" Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында" 2014 елның 24 июлендәге 75-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә эшләнгән.

1.2. Әлеге Тәртип белән Россия Федерациясе Конституциясендә беркетелгән Россия Федерациясе гражданинының (алга таба - гражданин) җирле үзидарә органнарына мөрәҗәгать итү хокукын гамәлгә ашыруга бәйле хокукый мөнәсәбәтләр җайга салына, шулай ук Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитетының вазыйфаи затларының гражданнар мөрәҗәгатьләрен карау тәртибе билгеләнә.

1.3. Гражданнар мөрәҗәгатьләрен карауның билгеләнгән тәртибе гражданнарның барлык мөрәҗәгатьләренә дә кагыла.

1.4. Тәртип Балтач муниципаль районы муниципаль берәмлегенең рәсми сайтында урнаштырыла.

## 2. Әлеге тәртиптә кулланыла торган төп төшенчәләр

2.1. Граждан мөрәҗәгате (алга таба - мөрәҗәгать) - җирле үзидарә органына яисә вазыйфаи затка язма рәвештә яисә электрон документ рәвешендә тәкъдим, гариза яки шикаять, шулай ук гражданның дәүләт органына, җирле үзидарә органына телдән мөрәҗәгате.

2.2. Тәкъдим - гражданның законнарны һәм башка норматив хокукый актларны камилләштерү, җирле үзидарә органнары эшчәнлеген камилләштерү, иҗтимагый мөнәсәбәтләрне үстерү, дәүләт һәм җәмгыять эшчәнлегенең социаль-икътисадый һәм башка өлкәләрен яхшырту буенча тәкъдиме.

2.3. Гариза - гражданның аның конституциячел хокукларын һәм ирекләрен яисә башка затларның конституциячел хокукларын һәм ирекләрен гамәлгә ашыруда ярдәм итү турында үтенече, яисә законнарны

һәм башка норматив хокукый актларны бозу, җирле үзидарә органнары һәм вазыйфаи затлар эшендә җитешсезлекләрне, яисә күрсәтелгән органнар һәм вазыйфаи затларның эшчәнлеген тәнкыйтьләү турында хәбәре.

2.4. Шикаять - гражданның аның бозылган хокукларын, ирекләрен яки законлы мәнфәгатьләрен яисә хокукларын, ирекләрен яки башка затларның законлы мәнфәгатьләрен торгызу яки яклау турында үтенече.

2.5.Вазыйфаи зат - вакытлыча яки аерым вәкаләт буенча хакимият вәкиле функцияләрен яисә җирле үзидарә органында оештыру-боеру, административ- хуҗалык функцияләрен башкаручы зат.

2.6. Коллектив мөрәҗәгать - ике яисә аннан да күбрәк гражданның мөрәҗәгате, гражданнар, шул исәптән юридик затлар берләшмәләренең мөрәҗәгате, шулай ук митингта яисә җыелышта катнашучылар тарафыннан тавыш бирү яисә имзалар җыю юлы белән кабул ителгән мөрәҗәгать аңлашыла.

## 3. Гражданнарныңмөрәҗәгатьитүхокукы

3.1. Гражданнар шәхси һәм күмәк мөрәҗәгатьләрне, гражданнар берләшмәләренең, шул исәптән юридик затларның мөрәҗәгатьләрен дә кертеп, дәүләт органнарына, җирле үзидарә органнарына һәм аларның вазыйфаи затларына, дәүләт һәм муниципаль учреждениеләргә һәм гавами әһәмиятле функцияләрне гамәлгә ашыру йөкләнгән башка оешмаларга һәм аларның вазыйфаи затларына мөрәҗәгать итәргә хокуклы.

3.2. Гражданнар мөрәҗәгать итү хокукын үзләре теләп һәм ирекле рәвештә гамәлгә ашыралар. Гражданнарның мөрәҗәгать итү хокукын гамәлгә ашыру башка затларның хокукларын һәм ирекләрен бозмаска тиеш.

3.3. Гражданнарның мөрәҗәгатьләрен карау бушлай башкарыла.

## 4. Гражданнарның мөрәҗәгатьләрен карауга бәйле хокук мөнәсәбәтләрен хокукый җайга салу

4.1. Гражданнарның мөрәҗәгатьләрен карап тикшерүгә бәйле хокукый мөнәсәбәтләр Россия Федерациясе Конституциясе, Россия Федерациясенең халыкара килешүләре, федераль конституциячел законнар, әлеге тәртип белән җайга салына.

4.2. Россия Федерациясе субъектларының законнары һәм башка норматив хокукый актлары гражданнарның мөрәҗәгать итүгә хокукларын яклауга юнәлдерелгән нигезләмәләрне, шул исәптән әлеге Нигезләмәдә билгеләнгән гарантияләрне өсти торган мөрәҗәгатькә гражданнарның хокуклары гарантияләрен билгеләргә мөмкин.

## 5. Мөрәҗәгатьнекараганда гражданнарныңхокуклары

Җирле үзидарә органы яисә вазыйфаи зат тарафыннан мөрәҗәгатьне

караганда гражданнар түбәндәге хокукларга ия:

1) өстәмә документлар һәм материаллар тапшырырга яисә аларны сорап, шул исәптән электрон формада да, мөрәҗәгать итәргә;

2) әгәр бу башка затларның хокукларына, ирекләренә һәм законлы мәнфәгатьләренә кагылмаса һәм күрсәтелгән документларда һәм материалларда дәүләт серен яисә федераль закон белән саклана торган бүтән серне тәшкил итмәсә, мөрәҗәгатьне карауга кагылышлы документлар һәм материаллар белән танышырга;

3) мөрәҗәгатьтә куелган мәсьәләләрнең асылы буенча, 2006 елның 2 маендагы 59 - ФЗ номерлы Федераль законның 11 нче статьясында күрсәтелгән очраклардан тыш, язмача җавап алырга, мөрәҗәгатьтә куелган мәсьәләләрне хәл итү компетенциясенә кергән дәүләт органына, җирле үзидарә органына яисә вазыйфаи затка язма мөрәҗәгатьне яңадан күчерү турында хәбәрнамә алырга;

4) мөрәҗәгатьне Россия Федерациясе законнары нигезендә административ һәм (яисә) суд тәртибендә карауга бәйле рәвештә мөрәҗәгать буенча кабул ителгән карарга яисә гамәлгә (гамәл кылмавына) шикаять белән мөрәҗәгать итәргә;

5) мөрәҗәгатьне карауны туктату турында гариза белән мөрәҗәгать итәргә.

## 6. Гражданнарның мөрәҗәгатенә бәйле рәвештә аларның иминлек гарантияләре

6.1. Гражданнарны җирле үзидарә органына яисә вазыйфаи затка күрсәтелгән органнарның яисә вазыйфаи затның эшчәнлеген тәнкыйтьләү белән мөрәҗәгать итүенә бәйле рәвештә яисә үз хокукларын, ирекләрен һәм законлы мәнфәгатьләрен яки башка затларның хокукларын, ирекләрен һәм законлы мәнфәгатьләрен торгызу яисә яклау максатларында эзәрлекләү тыела.

6.2. Мөрәҗәгатьне караганда мөрәҗәгатьтәге мәгълүматларны, шулай ук гражданинның шәхси тормышына кагылышлы белешмәләрне аның ризалыгыннан башка игълан итү рөхсәт ителми. Мөрәҗәгатьтә куелган мәсьәләләрне хәл итү компетенциясенә кергән җирле үзидарә органына яисә вазыйфаи затка язма мөрәҗәгать җибәрү мөрәҗәгатьтәге белешмәләрне тарату булып тормый.

## 7. Мөрәҗәгатьләргә карата таләпләр

7.1. Гражданнар язма, электрон, телдән мөрәҗәгать итәргә хокуклы.

7.2. Гражданнар үзләренең язма, электрон мөрәҗәгатьләрендә мәҗбүри тәртиптә мөрәҗәгатьләрне җибәрә торган дәүләт органы яисә җирле үзидарә органының исемен яисә тиешле вазыйфаи затның фамилиясен, исемен, отчествосын, яисә тиешле затның вазыйфасын, шулай ук үз фамилиясен, исемен, отчествосын (соңгысы булган очракта), җавап җибәрелергә тиешле почта адресын, электрон адресын, мөрәҗәгатьне яңадан

күчерү турында хәбәрнамәне күрсәтә, тәкъдим, гариза яки шикаятьнең асылын бәян итә. Язмача мөрәҗәгать иткәндә үз имзасын һәм датасын куя.

7.3. Дәүләт органына, җирле үзидарә органына яисә вазыйфаи затка электрон документ рәвешендә кергән мөрәҗәгать әлеге Федераль законда билгеләнгән тәртиптә каралырга тиеш. Мөрәҗәгатьтә гражданнар үзләренең фамилиясен, исемен, отчествосын (соңгысы булган очракта), җавап электрон документ рәвешендә җибәрелергә тиеш булса, электрон почта адресын һәм җавап язма рәвештә җибәрелергә тиеш булса, почта адресын мәҗбүри рәвештә күрсәтә. Гражданнар мондый мөрәҗәгатькә кирәкле документларны һәм материалларны электрон формада беркетергә яисә күрсәтелгән документларны һәм материалларны яки аларның күчермәләрен язма рәвештә җибәрергә хокуклы.

7.4. Кирәк булган очракта, гражданнар үз дәлилләрен раслау өчен язма яисә электрон мөрәҗәгатькә документлар һәм материаллар яки аларның күчермәләрен терки.

7.5. Гражданнар Татарстан Республикасы дәүләт телләрендә, туган телдә яки Россия Федерациясе халыкларының теләсә кайсы башка телендә тәкъдим, гариза, шикаять белән мөрәҗәгать итәргә хокуклы. Тәкъдимнәргә, гаризага, шикаятькә җаваплар гражданнарның мөрәҗәгать итү телендә бирелә. Мөрәҗәгать итү телендә җавап бирү мөмкин булмаган очракта, Татарстан Республикасының дәүләт телләре кулланыла.

7.6. Әгәр язма мөрәҗәгатьтә мөрәҗәгать җибәргән гражданнарның фамилиясе яки җавап җибәрелергә тиешле почта адресы күрсәтелмәгән булса, мөрәҗәгатькә җавап бирелми. Әгәр күрсәтелгән мөрәҗәгатьтә әзерләнә, кылына яисә кылынган хокукка каршы гамәлләр турында, шулай ук аны әзерләүче, кылучы яисә кылган зат турында белешмәләр булса, мөрәҗәгать дәүләт органына аның компетенциясе нигезендә җибәрелергә тиеш.

7.7. Язма мөрәҗәгать тексты укырлык булмаса, мөрәҗәгатькә җавап бирелми һәм аларның компетенциясе нигезендә органга яки вазыйфаи затка карап тикшерүгә җибәрелә алмый икән, бу хакта мөрәҗәгатьне теркәгән көннән җиде көн эчендә мөрәҗәгать иткән гражданга, әгәр аның фамилиясе һәм почта адресы укыла торган булса, хәбәр ителә.

7.8. Гражданнарның мөрәҗәгатьләрен тапшыру тәртибе белән беррәттән органга мөрәҗәгать итү вазыйфаи затка телеграмма яки факсимиль элемтә аша тапшырылырга мөмкин. Күрсәтелгән мөрәҗәгатьләр "Татарстан Республикасында гражданнар мөрәҗәгатьләре турында" Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында" 2014 елның 24 июлендәге 75-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы белән билгеләнгән язма мөрәҗәгатькә карата куела торган таләпләргә җавап бирергә тиеш.

## 8. Мөрәҗәгатьнекарауга кабул итүмәҗбүрилеге

8.1. Балтач муниципаль районы органына яисә вазыйфаи затына аларның компетенциясе нигезендә кергән мөрәҗәгать мәҗбүри рәвештә теркәлергә һәм каралырга тиеш.

8.2. Кирәк булган очракта, мөрәҗәгатьне карап тикшерүче орган яки вазыйфаи зат аны урынга барып карап тикшерүне тәэмин итә ала. Урынга чыгып мөрәҗәгатьне карауны оештыру тәртибе, шул исәптән аны уздыру сроклары, органнарның норматив хокукый актлары белән билгеләнә.

## 9. Вәкаләтләре туктатылган вазыйфаи затка адресланган гражданның мөрәҗәгатьләрен карау

9.1. Вәкаләтләре туктатылган вазыйфаи затка адресланган граждан мөрәҗәгате күрсәтелгән вәкаләтләрне гамәлгә ашыру йөкләнгән вазыйфаи зат тарафыннан карала.

9.2. Мөрәҗәгатьне теркәү мәҗбүри.

## 10. Язмамөрәҗәгатьне җибәрү һәм теркәү

10.1. Гражданнар язмача мөрәҗәгатьне турыдан-туры мөрәҗәгатьтә куелган мәсьәләләрне хәл итү компетенциясенә кергән органга яисә вазыйфаи затка җибәрә.

10.2. Татарстан Республикасы Балтач районы башкарма комитетының оештыру-гомуми бүлегендә органга яисә вазыйфаи затка кергәннән соң өч көн эчендә язма мөрәҗәгать мәҗбүри рәвештә теркәлергә тиеш.

10.3. Хәл ителеше әлеге орган яисә вазыйфаи зат компетенциясенә керми торган язма мөрәҗәгать, җитәкченең резолюциясе теркәлгән көннән җиде көн эчендә мөрәҗәгатьтә куелган мәсьәләләрне хәл итү компетенциясенә кергән тиешле органга яисә тиешле вазыйфаи затка җибәрелә, мөрәҗәгатьне җибәргән гражданнарга, әлеге Тәртипнең 7 нче пунктының 7.7. өлешендә күрсәтелгән очрактан тыш, мөрәҗәгатьне башка органга яисә вазыйфаи затка күчерү турында хәбәрнамә җибәрелә.

10.4. Язма мөрәҗәгатьтә куелган мәсьәләләрне хәл итү берничә орган яисә вазыйфаи зат компетенциясенә керсә, мөрәҗәгатьнең күчермәсе оештыру-гомуми бүлегендә теркәлгәннән соң җиде көн эчендә тиешле органнарга яисә тиешле вазыйфаи затларга җибәрелә.

10.5. Орган яисә вазыйфаи зат карап тикшерүгә язма мөрәҗәгать җибәргәндә, кирәк булган очракта, әлеге органнардан яисә вазыйфаи заттан язма мөрәҗәгатьне карау нәтиҗәләре турындагы документларны һәм материалларны соратып алырга мөмкин.

10.6. Карарына яки гамәленә (гамәл кылмавына) шикаять бирелә торган органга яки вазыйфаи затка карау өчен шикаятьне җибәрү тыела.

10.7. Әлеге статьяның 10.6 өлешендә каралган тыю нигезендә шикаятьне мөрәҗәгатьтә куелган мәсьәләләрне хәл итү компетенциясенә кергән органга яки вазыйфаи затка карап тикшерү өчен җибәрү мөмкин булмаса, шикаять гражданга аның тиешле карарга яисә гамәлгә (гамәл

кылмавына) карата хокукын яисә судка шикаять бирү хокукын аңлатып кире кайтарыла.

10.8. Электрон рәвештә җибәрелгән мөрәҗәгатьләр әлеге Тәртипнең 10 нчы пункты белән охшаш рәвештә теркәлә һәм җибәрелә.

## 11. Гражданнармөрәҗәгатьләренкараувакытлары

11.1. Барлык төр мөрәжәгатьләр - органга яки вазыйфаи затка аларның компетенциясе нигезендә кергән индивидуаль һәм коллектив мөрәжәгатьләр язма мөрәжәгать теркәлгән көннән алып 30 көн эчендә карала.

11.2. Аерым очракларда, шулайукәлегеТәртипнең 10 нчыпунктындагы 1 нче өлешендәкаралгансорауҗибәрелгәночракта, орган җитәкчесе, вазыйфаи зат яисә бу вазифага вәкаләтле зат мөрәжәгатьне карау вакытын 30 көннәндә арттырмыйча озайтырга хокуклы, ул мөрәжәгатьне җибәргән гражданнарга карау вакытын озайту турында хәбәр итәргә тиеш.

11.3. Мөрәжәгатьне карау нәтиҗәләре турында гражданнарга җавап аның буенча тиешле карар кабул ителгәннән соң өч көн эчендә, әмма әлеге пунктның 1нче һәм 2 нче өлешләрендә билгеләнгән вакытлардан да соңга калмыйча җибәрелә.

## 12. Гражданнарның мөрәжәгатьләрен карап тикшерү белән бәйле рәвештә билгеле булган мәгълүматларны органнар яки вазыйфаи затлар тарафыннан белдермәү

12.1. Гражданнар мөрәжәгатьләрен караганда мөрәжәгать иткән кешенеӊ ризалыгыннан башка аның шәхси тормышы турындагы мәгълүматларны кулану һәм тарату тыела, шулай УК аның фамилиясе, исеме, отчествосы, яшәү урыны, эш яки уку урыны турында мәгълүматлар тарату рөхсәт ителми.

12.2. Мөрәжәгатьне караганда мөрәҗәгатьтәге белешмәләрне игълан итү рөхсәт ителми. Мөрәҗәгатьтә куелган мәсьәләләрне хәл итү компетенциясенә кергән органга яки вазыйфаи затка язма мөрәҗәгать җибәрү мөрәжәгатьтәге мәгълүматларны тарату булып тормый.

## 13. Язма дәлилләр бирү бурычы

13.1. Орган яисә вазыйфаи зат билгеләнгән тәртиптә җибәрелгән мөрәжәгатьне карый торган орган яисә вазыйфаи зат соравы буенча 15 көн эчендә мөрәҗәгатьне карау өчен кирәкле документлар һәм материаллар, дәүләт серен яисә федераль закон белән саклана торган башка серне тәшкил итүче белешмәләр булган документлардан һәм материаллардан тыш, һәм аларны бирүнең аерым тәртибе билгеләнгән булмаса, бирергә тиеш.

13.2. Таләп ителә торган дәлилләрне белә торып тапшырмауда гаепле вазыйфаи затлар закон нигезендә җавап тота.

## 14. Гражданнарны шәхси кабул итүне оештыру

14.1. Органнарда гражданнарны шәхси кабул итү вәкаләтле затлар тарафыннан үткәрелә:

Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитеты җитәкчесе тарафыннан;

Башкарма комитет җитәкчесеурынбасарлары тарафыннан;

Гражданнарны шәхси кабул итүне оештырганда гражданнарны шәхси кабул итү тәртибенә карата "Россия Федерациясе гражданнары мөрәҗәгатьләрен карау тәртибе турында" Федераль законы белән билгеләнгән таләпләр исәпкә алына.

14.2. Кабул итү һәр сишәмбе 8.00 дән 11.00 сәгатькә кадәр, вәкаләтле затлар тарафыннан үткәрелә.

14.3. Кабул итүгә язылган гражданнарның һәрбнрсенә шәхси кабул итү картасы тутырыла (1 нче кушымта), анда күрсәтелә:

1) мөрәҗәгать иткән кешенең фамилиясе, исеме һәм отчествосы;
2) яшәү урынының адресы;
3) кабул итүче вазыйфаи затның фамилиясе;
4) башка кирәкле белешмәләр.

14.4. Шәхси кабул иткәндә гражданнар шәхесне раслаучы документ күрсәтә.

14.5. Телдән мөрәҗәгатьтә бәян ителгән фактлар һәм хәлләр ачык булса һәм өстәмә тикшерүне таләп итмәсә, мөрәҗәгатькә гражданнарның ризалыгы белән җавапны кабул итүне гамәлгә ашыручы вазыйфаи зат телдән бирелергә мөмкин, бу хакта шәхси кабул итү карточкасында язып куела. Калган очракларда мөрәҗәгатьтә куелган сорауларның асылы буенча язмача җавап бирелә.

14.6. Шәхси кабул итү барышында кабул ителгән язма мөрәҗәгать теркәлергә һәм "Россия Федерациясе гражданнары мөрәҗәгатьләрен карау тәртибе турында" Федераль закон һәм әлеге Тәртип белән каралырга тиеш.

14.7. Гражданнарны шәхси кабул итү өчен билгеләнгән көннәрдә һәм сәгатьләрдә органнарда беренче чиратта шәхси кабул итү хокукына ия:

а) I, I I төркем инвалидлар һәм (яки) аларның законлы вәкилләре (бер ата-ана, уллыкка алучылар, опекун яки попечитель);

б) Бөек Ватан сугышы ветераннары, Россия Федерациясе Геройлары, Советлар Союзы Геройлары, Социалистик Хезмәт Геройлары, Россия Федерациясе Хезмәт Геройлары, сугыш хәрәкәтләре ветераннары;

в) инвалид балалар, ятим балалар, ата-ана каравыннан мәхрүм калган балалар, ятим балалар һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар арасыннан затлар, шулай ук әгәр мондый балаларның хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен тәэмин итүгә һәм яклауга бәйле мәсьәләләр буенча мөрәҗәгать итсәләр балаларның законлы вәкилләре;

г) кабул итүгә өч яшькә кадәрге балалар белән килгән гражданнар.

14.8.Гражданнарны шәхси кабул иткәндә, 14.9 пунктындаа-г өлешендә күрсәтелгән гражданнар, аларны беренче чиратта шәхси кабул итүгә хокуклы

булуларын раслый торган документ күрсәтергә тиеш.

14.9. Органнар җитәкчеләре гражданнарны беренче чиратта кабул итү хокукына ия булган өстәмә гражданнар категорияләрен билгели алалар.

14.10. Беренче чиратта шәхси кабул итү хокукына бер үк вакытта берничә граждан ия булса, күрсәтелгән гражданнарны кабул итү аларның килүләре тәртибендә гамәлгә ашырыла.

## 15. Шикаять бирү хокукы

Гражданнарның тәкъдиме, гаризасы, шикаяте буенча кабул ителгән карар белән килешмәгән гражданнар әлеге шикаять белдерелә торган карарны кабул иткән орган яисә вазыйфаи зат буйсынган органга яки вазыйфаи затка яисә судка шикаять бирергә хокуклы.

## 16. Орган һәм вазыйфаи затның гаризаны карау буенча бурычлары

Вәкаләтенә гаризада каралган мәсьәләләрне карап тикшерү керә торган орган һәм вазыйфаи зат түбәндәгеләрне эшләргә бурычлы:

1) закон белән билгеләнгән вакытларда гаризаны карарга;

2) гражданнарның гаризасы буенча элек кабул ителгән карарларның үтәлешен исәпкә алырга;

3) нигезле карар кабул итәргә һәм аның үтәлешен тәэмин итәргә;

4) гариза биргән гражданнарга гаризаны карау нәтиҗәләре һәм аның буенча кабул ителгән карар турында законнарда билгеләнгән вакытта хәбәр итәргә;

5) гаризада бәян ителгән таләпләрне канәгатьләндермәгән очракта, гариза биргән гражданнарга язма рәвештә баш тарту сәбәпләрен җиткерергә, шулай УК гариза буенча кабул ителгән карар өстеннән шикаять бирергә мөмкин булган органны яки тиешле вазыйфаи затны күрсәтергә.

## 17. Мөрәҗәгатьне караганда гражданнарның хокуклары

Орган яисә вазыйфаи зат тарафыннан мөрәҗәгатьне караганда гражданнар түбәндәге хокукларга ия:

1) мөрәҗәгатьнекараучызаткадәлилләрнешәхсәнүзебәян итәргә;

2) органның тиешле структур бүлекчәсендә яисә тиешле вазыйфаи заттан язма мөрәҗәгатьне теркәү турында телдән (шул исәптән телефон буенча) яисә электрон формада, шулай ук аны карау вакытлары турында, мәгълүмат алырга;

3) язма мөрәҗәгатьне кабул иткән органның вәкаләтле заты (вазыйфаи зат) тарафыннан гражданнар тапшырылган икенче нөсхәдә датаны, фамилиясен һәм инициалларын күрсәтеп, язма мөрәҗәгатьне кабул итү фактын имза кую юлы белән таныклауга;

4) өстәмә документлар һәм материаллар тапшырырга яисә аларны сорап,

шул исәптән электрон формада да, мөрәҗәгать итәргә;

5) әгәр бу башка затларның хокукларына, ирекләренә һәм законлы мәнфәгатьләренә кагылмаса һәм күрсәтелгән документларда һәм материалларда дәүләт серен яисә федераль закон белән саклана торган бүтән серне тәшкил итмәсә, мөрәҗәгатьне карауга кагылышлы документлар һәм материаллар белән танышырга;

6) мөрәҗәгатьтә куелган мәсьәләләрнең асылы буенча, "Россия Федерациясе гражданнары мөрәҗәгатьләрен карау тәртибе турында" Федераль законның 11 нче статьясында күрсәтелгән очраклардан тыш, язмача җавап алырга, мөрәҗәгатьтә куелган мәсьәләләрне хәл итү компетенциясенә кергән органга яисә вазыйфаи затка язма мөрәҗәгатьне яңадан күчерү турында хәбәрнамә алырга;

7) мөрәҗәгать буенча кабул ителгән карарга яисә гамәлгә (гамәл кылмавына) Россия Федерациясе законнары нигезендә административ һәм (яисә) суд тәртибендә карауга шикаять белән мөрәҗәгать итәргә;

8) мөрәҗәгатьне карауны туктату турында гариза белән мөрәҗәгать итәргә;

9) мөрәҗәгать буенча кабул ителгән карарга шикаять бирергә;

10) вәкил хезмәтләреннән файдаланырга;

11) законнарда билгеләнгән тәртиптә мөрәҗәгатьне караганда органның яисә вазыйфаи затның законсыз гамәлләренә (гамәл кылмауларына) китерелгән зыянны каплауга һәм мораль зыянны компенсацияләүгә.

## 18. Шикаятьне карау буенча орган яки вазыйфаи затның бурычлары

Вәкаләтенә тиешле шикаятьне карау керә торган орган яисә вазыйфаи зат бурычлы:

1) шикаятьне кабул итәргә һәм теркәргә;

2) законнарда билгеләнгән вакытта шикаятьне карарга, шикаятьтә китерелгән барлык дәлилләрне һәм фактларны объектив һәм үз вакытында тикшерергә;

3) кирәк очракта, судлардан, алдан тикшерү органнарыннан һәм сорау алу органнарыннан тыш, башка органнардан һәм башка вазыйфаи затлардан мөрәҗәгатьне карау өчен кирәкле документларны һәм материалларны, шул исәптән электрон рәвештә дә, соратып алырга, шулай ук вазыйфаи затлардан аңлатмалар соратып алырга, шаһитларны һәм экспертларны чакырырга;

4) шикаять буенча РФ һәм ТР законнарына нигезләнгән һәм дәлилләнгән карар кабул итәргә һәм аның реаль үтәлешен тәэмин итәргә.;

5) гражданнарга шикаятьне карау нәтиҗәләре турында законнарда билгеләнгән вакытта мөрәҗәгатьтә күрсәтелгән почта адресы буенча язмача, мөрәҗәгатьтә күрсәтелгән электрон почта адресы электрон документ рзвешендә яисә аның белән килешү буенча телдән хәбәр итәргә.

## 19. Шикаять буенча карар

Шикаять буенча карарда карар нигезенә салынган мотивлар һәм фактлар, законның яисә башка норматив хокукый актның конкрет статьяларына сылтамалар; кирәкле очракларда шикаять белдерелә торган карарны гамәлдән чыгару яисә үзгәртү турында күрсәтмә, кабул ителгән карарны үтәү срогы; законсыз карар кабул иткән яисә законсыз гамәл кылган (гамәл кылмаган) вазыйфаи затны җаваплылыкка тарту кирәклеге турында күрсәтмә, шулай ук кабул ителгән карарга шикаять бирү тәртибе булырга тиеш.

## 20. Шикаять буенча карар кабул итү нәтиҗәләре

20.1. Шикаять тулысынча яисә өлешчә канәгатьләндерелергә тиеш дип табылса, шикаять буенча карар чыгарган орган яисә вазыйфаи зат гражданнарның бозылган хокукларын торгызу буенча кирәкле чаралар күрергә, шулай ук гражданнарның үтенече буенча кабул ителгән карар турында кызыксынган затларга хәбәр итәргә тиеш.

20.2. Дөрес булмаган яисә гражданнарның исеменә тап төшерә торган белешмәләр массакүләм мәгълүмат чараларында басылып чыккан булса, әлеге мәгълүматларны биргән орган яисә вазыйфаи зат законнарда билгеләнгән тәртиптә кире кагуны бастырып чыгару буенча чаралар күрергә тиеш.

## 21. Органнарының "турыдан-туры линия" һәм "кайнар линия" телефоннары буенча кабул ителгән гражданнарның мөрәҗәгатьләрен карау

21.1. Органнар, гражданнарның үз эшчәнлекләре турында мәгълүмат алуга хокукларын гамәлгә ашыруны тәэмин итү максатларында, шулай ук гражданнарның мөрәҗәгатьләрен кабул итү өчен "турыдан-туры линия" һәм "кайнар линия" эшен оештыра ала.

21.2. Органнарның "турыдан-туры линия" һәм "кайнар линия" телефоннары буенча кабул ителгән мөрәҗәгатьләр РФ һәм ТР законнарында һәм әлеге Тәртиптә билгеләнгән вакытта теркәлергә тиеш.

21.3. Вазыйфаи зат органы, "турыдан-туры линия" һәм "кайнар линия" телефоннары буенча мөрәҗәгатьләрне кабул итүне гамәлгә ашыручы вәкил, гражданнарның мөрәҗәгатен терки һәм мөрәҗәгать итүченең элемтә өчен телефонын һәм (яки) электрон почта адресларын (алар булган очракта), мәсьәләнең асылын, мөрәҗәгать итүнең датасын һәм вакытын күрсәтеп мөрәҗәгатьнең электрон карточкасын формалаштыра.

21.4. Электрон карточкадагы белешмәләр мөрәҗәгатьтә куелган мәсьәләләрне хәл итү компетенциясенә кергән тиешле органнарга җибәрелә.

21.5. "Турыдан-туры линияләр" һәм "кайнар линияләр" эше кабул итүче органнар тарафыннан норматив хокукый актлар нигезендә башкарыла.

## 22. Күмәк мөрәҗәгатькә язмача җавап алу өчен гражданнарның хокукларына өстәмә гарантияләр

22.1. Гражданнарның күмәк мөрәҗәгатенә язмача җавап, мөрәҗәгатьтә җавапны алучы итеп күрсәтелгән яисә мөрәҗәгатькә кул куйган гражданнар коллективы вәкиле сыйфатында күрсәтелгән затка җибәрелә.

22.2. Әгәр җавап алучы күмәк мөрәҗәгатьтә билгеләнмәгән булса, җавап яшәү урынын күрсәткән мөрәҗәгать итүчеләр (имза куючылар) исемлегендә күрсәтелгән беренче гражданга җибәрелә.

22.3. Коллектив мөрәҗәгатькә җибәрү турындагы үтенеч берничә мөрәҗәгать итүче (имза куючылар) тарафыннан белдерелгән булса, җавапның күчермәсе аларның һәркайсына күрсәтелгән почта адреслары буенча җибәрелә.

## 23. Коррупцион юнәлештәге фактлар буенча гражданнар мөрәҗәгатьләрен карау

23.1. "Коррупциягә каршы көрәш турында" 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль закон һәм "Татарстан Республикасында коррупциягә каршы тору турында" 2006 елның 4 маендагы 34-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә гражданнар коррупциячел юнәлештәге фактлар буенча мөрәҗәгатьләрне органнарга җибәрергә хокуклы.

23.2. Коррупция юнәлешендәге фактлар буенча гражданнарның мөрәҗәгатьләре үз эченә коррупция фактлары һәм янап акча алу, гражданнарның хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен кысу, хезмәт тәртибенә карата таләпләрне бозу, шулай ук хезмәт урыныннан явызларча файдалану билгеләрен үз эченә алган бүтән гамәлләр кылу турында белешмәләрне ала.

23.3. Кергән мөрәҗәгатьтә әзерләнә, кылына яки кылынган хокукка каршы гамәл турында, шулай ук аны әзерләүче, башкаручы яки кылган зат турында мәгълүмат булганда, мондый мөрәҗәгать хокук саклау органнарына аларның компетенциясе нигезендә җибәрелә.

23.4. Коррупция юнәлешендәге фактлар буенча гражданнарның мөрәҗәгатьләре белән эшләүче вазыйфаи затлар билгеләнгән тәртиптә Россия Федерациясе законнары нигезендә хезмәт мәгълүматын һәм конфиденциаль характердагы белешмәләрне саклау өчен шәхси җаваплылык тоталар.

23.5. Коррупция юнәлешендәге фактлар гражданнарның мөрәҗәгатьләре белән эшләү тәртибе органнарның норматив хокукый актлары белән билгеләнә.